ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.04.2024 ел Баулы шәһәре №48

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 февралендәге 20 номерлы карары белән расланган, 2024 елның язгы чорында («Ташу – 2024» планы) су басу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү буенча Баулы муниципаль районының эш Планына үзгәрешләр кертү турында

Федераль законның 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 февралендәге 20 номерлы карары белән расланган, 2024 елның язгы чорында («Ташу – 2024» планы) су басу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү буенча Баулы муниципаль районының эш Планына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

VIII «Матди-техник, азык-төлек, медицина тәэмин итүен оештыру» бүлегенең 8.4 өлешендә «Зыян күргән халыкны кайнар ризык, беренче кирәк-яраклар белән тәэмин итү» сүзләре «Баулы» ПО, «Татнефть-УРС» ҖЧҖ тарафыннан азык-төлек товарлары һәм беренче кирәк-ярак товарлары белән тәэмин итүчеләр булып тора». Зыян күрүчеләрне һәм эзләү-коткару операцияләрендә катнашучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү шулай ук, Баулы шәһәрендәге «Буровик» һәм «Колос» ашханәләренә йөкләнгән сүзләрен «Азык-төлек товарлары китерүне, азык-төлек оештыруны һәм зыян күрүчеләрне һәм эзләү-коткару операцияләрендә катнашучыларны эчемлек белән тәэмин итүне Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты һәм «Гранд» ҖЧҖ арасында төзелгән хезмәтләр күрсәтү килешүе нигезендә» сүзләре белән алыштырырга»;

«Баулы муниципаль районының күчмә туклану пункты (алга таба – ППП), азык – төлек белән тәэмин итүнең күчмә пункты (алга таба-ППС), әйберләр белән тәэмин итүнең күчмә пункты (ППВС) буенча мәгълүматлар» Планына 5-нче кушымта, үз көчен югалткан

дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров